| | |
|---|---|
| СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ТИМЯШЕВСКОЕСЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ «ТИМӘШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2022 елның 17 марты № 7

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Тимәш авыл җирлеге Советының 2013 елның 18 декабрендәге 31 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Тимәшавыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 6 декабрендәге 408-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 декабрендәге 476-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Тимәш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Тимәш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Тимәш авыл җирлеге Советының 2013 елның 18 декабрендәге 31 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Тимәш авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 статьяны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«блокланган төзелеш йорты – башка торак йорт (башка торак йортлар) белән бер рәттә гомуми ян стенасы (гомуми як стеналары) белән блокланган һәм җир кишәрлегенә аерым чыгу урыны булган торак йорт.»;

22 статьяның 2 өлешенең 6 абзацын «,шул исәптән Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 52 статьясындагы 11 өлешендә күрсәтелгән очракта;» сүзләре белән тулыландырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Тимәш авылы, Утыз Имәни урамы, 71Д (җирле үзидарә бинасы), Киров урамы, 26 (мәдәният йорты), нефтьүткәргечләр урамы, 20 (Ромашкино РНУ утырышлар залы), Киров урамы, 1А («Ласточка» балалар бакчасы), Лесная урамы, 20, Лесная урамы,33 адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.r) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Лениногорск муниципаль районы
«Тимәш авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе Р.М.Сираев